**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район,
село Атабаево , ул.Молодежная , дом 1,
тел: 8(84378)-4-87-41
факс: 8(84378)4-87-41

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
Яшьләр урамы , 1нче йорт
тел: 8(84378)-4-87-41
факс: 8(84378)-4-87-41

**№ 127** **2019 елның 12 мартыннан**

# КАРАР

**Атабай авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 ноябреннән №117 “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт хакында Кагыйдәләр турында”гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2007 елның 2 мартыннан № 25-ФЗ “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законны, 2008 елның 25 декабреннән № 273-ФЗ “ Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июненнән № 50-ЗРТ Кодексы, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге” Уставы нигезендә Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Атабай авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 ноябреннән № 117 “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт хакында Кагыйдәләр турында”гы Карарына кушымтага ярашлы төстә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга) һәм җирлек территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

**Башлык – Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Атабай авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.Р.Хәлилова**